Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
«Апаз балалар бакчасы » муниципаль бюджет
мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

3 сан
Январь 2025



# ЧИШМӘ БАШЫ

Бакчабызның бүгенгесен яктыртучы мәгълүмати электрон газетасы

Газетаның сәхифәсе;

*Кыргый хайваннар кыш коне
*Табышмаклар өйрәнәбез
* Кыргый хайваннар турында
* Кыргый хайваннар белән уеннар

Баш мөхәррир- бакча мөдире : Зайнуллина Индира Тәлгать кызы
Мөхәррир урынбасары тәрбияче: Нигъмәтҗанова Лилия Гаптеләхәт кызы.

# *Кыргый хайваннар кыш коне*

Бар дөньяны сихри ап-ак матурлыкка тореп, кар-бураннарын туздырып, салкыннары белән кыш хакимлек итә. Урманнар, кырлар, тау битләре, елга-күлләр, барысы да ак кар белән капланды.

Яңа яуган кар өстендә куянкайларның, төлкеләрне, тиеннәрнең, бүреләрнең эзләре ярылып ята. Куяннар кышка ничек эзерләнәләр.Алар соры туннарын ак тоскә алыштыралар. Шулай итеп ерткычларлардан саклананалар. Куяннар кыш көне агач ботаклары, кайрылары, кипкән үләннәр белән туклананалар. Төлкеләр төсен үзгәртмиләр. Алар үзләре ерткыч хайван. Толкеләр җирне казып оя ясыйлар, шунда йоклыйлар. Алар куяннарны, тавыкларны аулыйлар. Аюлар кыш көне йоклап уздыралар, аны уятырга ярамый. Аю көздән күп итеп ашый, шулай итеп май катламы җыя. Аюнын төп эше - каты йокыга талу һәм яз килгәнен көтү. Аю ерткыч хайван булсада- үлән, бал, җиләк, гомбә белән туклананалар. Суда бик оста йөзәләр, бик тиз йөгерәләр.
Безнен якларда соры бүреләр яши. Бүре этнең ерак бабасы.Ул ерткыч хайван., бик тиз йогерә. Борыны бик сизгер бармак очларында тавышсыз йөгерәләр. Алар авыру хайваннарны аулыйлар. Бүреләр торкем булып яшиләр, торкем булып ауга чыгалар. Поши,болан, сарык, кабан аулыйлар.

# *Хайваннар турында табышмаклар*

Җәен соры, кышын ак
Аңа шулай яхшырак.(Куян)

Кош түгел - оча
Ябалактан курка.
Чикләвек ярата
Сызгырса урманны яңгырата. (Тиен)

Асрамый умарта
Балны бик –бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача йоклап ята.( Аю)

Урманда гомер итә ул
Мөгезе тармактармак.(Поши)

Сорыдыр тосе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Сарыклар эзли.( Бүре)

Урманнан чыгар,
корсак асты чуар,
Койрыгы сырлы.
Хәйләсе күп төрле.( Төлке)





# Кыргый хайваннар







## Кыргый хайваннар

**Куян (заяц)**

Кышын куяннар кешеләргә якынрак күчәләр. Алар кышка йомшак куе йон белән капланалар.





**Тиен (белка)**

Тиенне кыш көне суык та, җил дә куркытмый. Алар кышка азык туплыйлар.

## Кыргый хайваннар

- Безнең урманнарда очрый торган иң эре ерткыч – аю. Кышын аюга азык калмый. Шуңа күрә алар кышны йоклап үткәрәләр. Көзен аюлар бик күп ашап, май җыялар, симерәләр. Кайберәүләр, өнендә аю тәпиен суырып ята, дип уйлыйлар. Тәпиенең тиресе корый, ярглана, кычыта. Шуңа күрә аю йокы аралаш тәпиен ялап куя. Аюның балалары февральдә үк туа.

**Аю (медведь)**



## Кыргый хайваннар

**Төлке (лиса)**



- Бүреләр белән төлкеләр - якын туганнар. Куянның иң куркыныч дошманы дип төлке санала. Ләкин төлкенең төп азыгы – тычканнар. Төлкенең эзләре кечкенә этнекенә охшаган. Ләкин этләр бераз як-якка атыныбрак йөри, шуңа күрә әгәр аларның эзләрен тоташтырсаң, сынык сызык килеп чыга. Ә төлке эзләре туры сызык ясый.

# *Кыргый хайваннар белән уеннар*

«Куяннар һәм бүре” уены :Бер бала бүре,калганнары куяннар була.Уен барышында куяннар үз урыннарында утыралар,ә бүре икенче якта утыра.
Тәрбияче: Ямьле болында куяннар
Сикергәләп йөриләр.
Як-якларына каранып,
Бүре килүен күзлиләр.
Куяннар урыннарыннан чыгып уйныйлар, ә бүре урыныннан чыгып, куяннарны тотмакчы була.Куяннар үз урыннарына йөгерәләр.Тотылган куянны бүре үз оясына алып китә.
“Аксак төлке” уены:Аксак төлке белән өй хуҗасы сайлана, башка балалар,тавыклар булып, зур түгәрәк эченә кереп басалар. Сорауларга җавап биреп уйныйлар.Аксак төлке, ялгышып икенче аягы белән җиргә баса, хуҗа аны күреп куа башлый. Тотса толкегә җәза бирелә.
“Бармак” уены: Баш бармагым бүредер,
Имән бармагым – төлке,
Урта бармагым- бурсык,
Атсыз бармагым – аю,
Чэнти бармагым – куян,
Куянны кая куям ?